ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Янгын куркынычсызлыгы турында” Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

## 1 статья

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; 1994, № 1 – 2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Хосусый янгыннан саклануның саны һәм техник тәэмин ителеше нормативлары аның милекчесе тарафыннан, янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар таләпләрен исәпкә алып, ирекле нигездә билгеләнә.”;

2) 19 статьяда:

а) икенче өлештә “мөлкәтне коткару һәм (яисә)” сүзләреннән соң “шартлау куркынычы булган предметлар,” сүзләрен өстәргә;

б) өченче өлештә “янгыннан саклану гарнизоннары” сүзләрен “янгыннан коткару гарнизоннары” сүзләренә алмаштырырга.

## 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 79-ТРЗ